**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«14» 06 2024 ел          Яр Чаллы шәһәре          № 2859

Кече Шилнә авыл җирлегендә 16:39:102301:155, 16:39:102301:435 кадастр номерлы җир кишәрлекләре территориясен яңадан бүлү максатыннан ызанлау проектын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, 2024 елның 11 июнендәге халык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә

## КАРАР БИРӘ

1. Кече Шилнә авыл җирлегендә 16:39:102301:155, 16:39:102301:435 кадастр номерлы җир кишәрлекләре территориясен яңадан бүлү максатыннан ызанлау проектын расларга.
2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе          А.Р. Хәбибуллин